| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.12.2021 № 694-осн

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына буйсына торган урманчылыкларда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 96 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) турында» 2021 елның 30 июнендәге 1098 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына буйсына торган урманчылыкларда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген (кушымтада бирелә) (алга таба – Исемлек) расларга.
2. Исемлектә санап үтелгән вазыйфаи затларга федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман сагын гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нормаларына таянып эш итәргә.
3. Юристлар бүлегенә (В.В.Мәниховага) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.
4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2021 елның
20 декабрендәге 694 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына буйсына торган урманчылыкларда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыкларның җитәкче-урманчылары | Татарстан Республикасының өлкән дәүләт урман инспекторлары |
| Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыкларның җитәкче-урманчылары урынбасарлары | Татарстан Республикасы өлкән дәүләт урман инспекторлары урынбасарлары |
| Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыкларның белгечләре:<br>кишәрлекләрдәге урманчылар;<br>инженерлар;<br>урман осталары | Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторлары |